**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 2 сентябрь № 643

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый совет турында» 2010 ел, 18 ноябрь, 906 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый совет хакындагы бертип нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый совет турында» 2010 ел, 18 ноябрь, 906 нчы карары белән расланган (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 15 октябрь, 856 нчы; 2013 ел, 24 октябрь, 793 нче, 2014 ел, 20 сентябрь, 669 нчы, 2015 ел, 14 май, 341 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый совет хакындагы бертип нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1 пунктта «социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар» сүзләрен «иҗтимагый оешмалар, шулай ук дәүләтнеке булмаган коммерциягә карамаган оешмалар» сүзләренә алмаштырырга;

3.3 пунктта «иҗтимагый оешмалар вәкилләре арасыннан гражданнар, шул исәптән социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешма вәкилләре» сүзләрен «гражданнар, шул исәптән иҗтимагый оешмалар һәм бүтән социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар вәкилләре булган» сүзләренә алмаштырырга;

3.6 пунктка түбәндәге эчтәлекле яңа абзац өстәргә:

«алар икеләтә гражданлык алу.»;

3.8 пунктның дүртенче абзацында «кандидат вазыйфасына» сүзләрен төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков